ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында» 2023 елның 13 июлендәге 2088-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын үтәү барышы хакында

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары А.Х. Садыйковның «Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында» 2023 елның 13 июлендәге 2088-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын үтәү барышы хакындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары А.Х. Садыйковның «Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында» 2023 елның 13 июлендәге 2088-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын үтәү барышы хакындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына «Татарстан Республикасы Пространство планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе катнашында Татарстан Республикасы территориясендә территорияләрнең пространство бәйләнешен һәм транспорттан файдалана алу мөмкинлеген һәрьяклап анализлау нигезендә транспорт үстерүнең стратегик юнәлешләрен булдыруны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына, тармак экспертлар бергәлеген җәлеп итеп, Татарстан Республикасы профильле башкарма хакимияте органнары белән берлектә транспорт өлкәсендәге законнарны мониторинглауны дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 29 мае
№ 2464-VI ДС